Бөтендөнья татар конгрессы

киңәйтелгән утырышының семинар-совещаниесе

*("Казан" милли мәдәният үзәге)*

29.11.2017 Казан шәһәре

**Данис Шакиров**: Хәерле көн! Сезне семинар-киңәшмәдә сәламлибез. Кичә инде сезне Васил Габтелгаязович тә сәламләде, Ринат Зиннурович белән дә бик күбегез күреште. Без бүгенге көнне менә шушы семинар-киңәшмә белән башлап җибәрәбез. Без сезнең белән барыгыз белән дә таныш. Мин инде Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Зиннурович Закировның беренче урынбасары Шакиров Данис Фәнисович булам.

Без бүген семинар-киңәшмәдә төп 2 тема билгелибез. Ул, әлбәттә, сезнең мөрәҗәгатьләрдән соң, сезнең тәкъдимнәрдән соң, фикерләрдән соң, чөнки эшләү дәверендә хәзер билгеләнәчәк ике тема буенча шактый гына сораулар туа. Беренчедән, ул грантлар тапшыру мәсьәләсе, мин кыскача гына теоретик материалны бирсәм, безнең менә иң актив бу юнәлештә ике оешма җитәкчесе практик ягына сөйләячәкләр. Һәм икенче мәсьәлә ул безнең татар оешмаларын теркәү һәм хисап бирү мәсьәләсе.

Шуңа күрә бу ике мәсьәлә буенча аерым мин үзебезнең дә юристка һәм шулай ук безнең Юстиция министрлыгының коммерцияле булмаган оешмалар эше бүлегенең дә белгечен чакырдык. Ул да сезгә аерым ачыклык кертер. Беренче мәсьәлә буенча проектларны тапшыру буенча кыскача гына башта мәгълүмат биреп алам.

Менә бу грантлар Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән бергә тапшырыла. Сезнең турыдан-туры катнашыгызда татар халкының рухи мирасын саклау һәм Татарстаннан читтә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү буенча без, әлбәттә, татар оешмалары аркылы системалы эш алып барабыз.

Россиядә һәм чит илләрдә мәдәни проектларны тормышка ашырганда татарларның югары активлыгын, институт вәкиллегенең республика дәүләт хакимияте органнары, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, татарларның Федераль милли-мәдәни мохтарияты, Россия төбәкләрендә һәм чит илләрдә татар иҗтимагый оешмалары белән тыгыз бәйләнешен да әйтеп үтәргә кирәк.

Безнең ватандашлар республиканың сизелерлек дәүләт ярдәмен билгеләп үтәләр, бу - ватандашларыбызга ярдәм итү мәсьәләсендә системалы дәүләт мөнәсәбәте нәтиҗәсе.

Татар иҗтимагый оешмалары проектларына дәүләт ярдәме 2012 елдан башкарыла һәм иң элек Федераль милли-мәдәни автономиясе составына керүче Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар милли-мәдәни автономияләре проектларына юнәлтелгән булган.

2014 елдан башлап грант конкурсы Дәүләт программасы чаралар исемлегенә керә "Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014-2019 еллар)". Ул башта 2014-2016 елларда хәтле иде. Хәзер ул дәвам итте 2019 елга хәтле. Һәм ул төбәк татар автономиясенә генә түгел, ә Россия төбәкләрендә татар теле, әдәбият һәм мәдәният үсеше белән шөгыльләнүче барлык иҗтимагый оешмаларга да үтәрлек булды. Димәк, барлык татар оешмалары, әлбәттә, безнең Юстиция министрлыгында теркәү узган оешмалар да, шушы грантарга ия була ала. Чөнки грантлар Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Президенты ярдәмендә тапшырыла.

2015 елда грантлар бирү тәртибе №328 нче карар белән 06.05.2015 Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты белән расланган. Әлеге карар белән шулай ук грантлар бирү буенча Совет составы да расланган. Һәрбер елны экспертлар советы үзгәреп бара. Моңа хәтле ул Мәдәният министры Айрат Миңнемуллович Сибагатуллин җитәкчелегендә барды. Һәрбер оешмадан экспертлар советы, татар оешмаларыннан түгел, ә

безнең Татарстандагы, Казандагы министрлыклар, ведомстволарның вәкилләре булды. Шул исәптән конгрессның вәкиле дә.

Конкурста катнашуга законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм бәйгедә сайлап алу игълан иткән көнгә кадәр кимендә 1 елга кадәр эшчәнлек алып баручы, киләчәк буыннарда татар халкының мәдәни мирасын, телен, тарихын пропагандалау, татар мәдәниятенең этник тәңгәллеген формалаштыру буенча устав нигезендә булган социаль, мәгълүмати, мәдәни, белем бирү, фәнни функцияләрне башкару төп максат булып тора.

Грант бирү шартының берсе булып бюджеттан тыш чыганаклар хисабына проектны тормышка ашыруда гомуми сумманың чыгымнары 20% тан да ким булмаган финанслау буенча иҗтимагый оешмаларның йөкләмәсе тора.

Ел саен финанслау күләме – 5 млн. Сум иде моңа кадәр. Ләкин мин ахырда әйтермен, безнең бу сумма үзгәрәчәк. Бу вакыт эчендә 157 иҗади идеяләрне урыннарда гомуми 30 млн. сумга тормышка ашырырга насыйп булды.

Татар иҗтимагый оешмалары белән бүлеп бирелә торган субсидияләр кысаларында тормышка ашырылган күпчелек этномәдәни проектлар фестивальләр, бәйгеләр, конференцияләр үткәрүгә, китаплар һәм белешмәлекләр нәшер итүгә, иҗади сменалар һәм татар мәдәнияте көннәрен оештыруга юнәлтелгән.

2017 елда 30 татар иҗтимагый оешмалары грантлар алды. 2012 ел белән чагыштырганда грантлар бәйгесендә катнашкан татар иҗтимагый оешмаларының саны 28 гә артты (2012 елда – 22, 2017 елда – 50), бәйгедә җиңүчеләр саны арта (2012 елда – 21, 2017 елда – 30). Шулай ук грант бәйгесендә катнашучыларның географиясе киңәйде, (2012 елда – Россия Федерациясенең 22 төбәгендә, 2017 елда – 31 төбәгендә). Игълан ителгән проектларның уртача бәясе 500 мең сум тәшкил итә (чагыштыру

өчен, 2012-2014 елларда проектның гомуми бәясе 250-300 мең сум тәшкил итте).

Гаризаларны бәяләү 10 баллы шкала буенча башкарыла. Түбәндәге төркем критерийлар буенча: проектның әһәмияте һәм актуальлеге критерийлары, икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеге, һөнәри компетенция һәм өстәмә критерийлары.

Грантлар алганда гаризалар тикшергәндә барлыкка килгән төп проблемалы нокталар: чыгымнар сметасы югары, проектны тормышка ашыру схемасы өйрәнелмәгән, максатсыз акча куллану (җиһазлар сатып алу маддәсе), бәйгенең бурычларына туры килмәве.

Иҗтимагый оешмалар арасында грантларны бүлү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла: грантның гомуми күләме (5 млн. сум) барлык иҗтимагый оешмалар белән тупланган баллар суммасына бүленә һәм бер иҗтимагый оешма белән тупланган балларның гомум суммасына тапкырлана.

Әлеге формулада, шулай ук ел саен гаризаларның артуын һәм җиңүчеләрне исәпкә алып, грант ярдәме күләме һәр проектка кими бара (уртача грант күләме 2017 елда 140 меңнән 180 мең сумга кадәр үзгәрә).

Бу акрынлап проектларны тормышка ашыру сыйфатына йогынты ясый башлый, ә кайбер очракларда проектны тормышка ашыру бөтенләй мөмкин булмый. Бу, барыннан да элек, китаплар нәшер итү һәм массакүләм этномәдәни чаралар үткәрү проектларына кагыла. Шулай ук грант алучыларның саны фиксацияләнгән, елына – 30 дан артмаска тиеш.

Шулай ук билгеләп үтәсем килә, расланган тәртип нигезендә, грантлар Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә иҗтимагый оешмаларга бирелә. Шулай ук автономияләр дә һәм башка исем астында регистрация узган оешмалар да бу грантларда катнаша ала.

2017 елда Килешүнең 2 формасы расланды: 1 – финанс белән тәэмин итү чыгымнары; 2 – чыгымнарны каплау. Әлеге Килешүләрдә мәҗбүри шарт булып, проектны гамәлгә ашыргында кимендә 3

күрсәткече булган  формалар тутыру тора. Грант алучылар 1 декабрьгә кадәр фото-, видеоматериаллар һәм үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре хакында аналитик белешмә, шулай ук Килешү буенча күздә тотылган хисап турындагы ирешү күрсәткечләренең нәтиҗәлелеге буенча грантны максатлы файдалану турында хисап тапшыралар.

Хөрмәтле коллегалар! Сезнең игътибарны шуңа юнәлтергә телим. Елдан-ел берничә татар иҗтимагый оешмалары грант бәйгесенә  бер үк проект белән киләләр. Сезгә шундый мөрәҗәгать белән чыгам:  алга таба татар теле, әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә шактый зур өлеш кертүче яңа иҗади проектларны гамәлгә ашырганда активлашырга. Грантның күләме 10 миллионга хәтле күтәреләчәк. Бу, димәк, һәрбер проектка биреләчәк акчасы да һәм гомумән саны да арта дигән сүз.

Бу, әлбәттә, теория. Мин сезгә әйтеп узган кыскача гына теоретик материал. Мәдәният министрлыгы белән бергә эшли торган милли-мәдәни федераль автономиясе белән бергә эшли торган. Ләкин аның практик өлеше бар. Һәм практик өлешенә күчкәндә шактый гына сораулар туа. Әлбәттә, тутырган вакытта гына, һәрбер детален өйрәнгән вакытта, һәрбер эш кәгазен тутырган вакытта туа торган сораулар бар. Ләкин мин шушы семинар-совещание кысаларында бүген 2 кешегә чыгыш бирәсем килә бу мәсьәлә буенча.

Беренчедән, Мохтасаров Фәрит Шамиль улы – Мәскәү өлкәсе Төбәк татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе. Бүгенге көндә бик актив бу эштә катнаша. Татарстан Республикасының грантларын гына түгел, Мәскәүдә һәм Россия Федерациясе тарафыннан тапшырыла торган грантлар системасын да бик яхшы белән һәм файдалана ала. Шуның ярдәмендә бик актив шушы чараларны уздыра алалар. Шуңа күрә, әйдәгез, менә шушы семинар-совещаниене формаль бер киңәшмә буларак үткәрмик. Менә монда оешма җитәкчеләре, бу эш белән шөгыльләнүче кешеләр утырган. Өстәмә сораулар биргән вакытта да практик өлешенә күчик. Фәрит Шамил улы, сүз сезгә. Рәхим итегез!

**Фәрит Мохтасаров**: Хөрмәтле дуслар, беренчедән, миңа бүген шундый почетный урын, Президиумга утырттылар чыгыш ясаучы булгач. Шуңа күрә трибунага чыккач, сезне барыгызны да башта сәламлисе килә. Әле бөтенегез белән дә күрешеп өлгермәдек. Барыгызга да сәлам. Безнең мондый очрашулар безгә һәрвакытта дәрт бирә. Монда килеп, без шулай ук тәҗрибә алып китәбез һәм безгә ул киләчәктә дә эшләргә ярдәм итә. Шуңа күрә безнең әлеге сөйләшү дә файдага китсен иде. Мин үземнең тәҗрибәне, әлбәттә, әйтәчәкмен. Сорауларыгыз булса, бирерсез. Барыбызга да файдасы булсын.

Безнең Татарстанда Мәдәният министрлыгы белән эшләгән грантны әйтеп китәм башта. Быелгы грант безнең “Школа формирования лидеров татарской молодежи” дип аталды. Шуңа күрә без аны уйлаганда да ул безнең инде күптәннән уйлап килгән эш иде, проект. Аны безнең яшьләр, Мәскәү өлкәсе яшьләре, андагы болай оешып эшләгән яшьләр дә, күпләр шундый форум уздырырга уйлап йөриләр иде.

Аларны мин бераз җыйдым да, мин әйтәм: “Менә безнең бераз мөмкинчелек бар, менә шушы Татарстан аркылы әйдәгез әле проект язып карыйк”, -дидем. Һәм яшьләр белән бергә шул проектны яздык, җибәрдек һәм безгә 170 мең акча бирделәр, шушы грантка инде. Безнең проект буенча ул инде яз көне үк башлана. Аның исеме “Форум Урманкүл” дип атала. Ул җәй көне үк башлана. Анда теплоходта йөреп, мастер-класслар уздырып, проектның төп өлеше – көз көне октябрь аенда Мәскәү өлкәсендә зур форум уздыру.

Менә шул зур форумга килеп терәлгәч, теге җәйгеләре барды, советларын ясадык. Шул форум Мәскәү өлкәсендә Дмитров районында без пансионатта уздырдык. Яшьләр килделәр төрле яктан, Мәскәү өлкәсе, Мәскәүдән. Хәтта Екатеринбургтан, Төмәннән дә килделәр мастер-класс уздырырга. 2 көн шул пансионатта төрле темага багышланган мастер-класслар үтте. Җитәкчелек буенча да, матур сөйләү буенча да, татар теле буенча да бик файдалы, матур булып узды.

Мин үзем яшьләр белән башыннан азагына хәтле булдым. Шуңа күрә үзем дә яшәреп киттем алар белән йөри-йөри. Бик әйбәт, бик матур булды. Проектның ахырында шулай ук планга кертелгән иде, Мәскәүдә яңа төзелгән мәчеткә барып, андагы җитәкчеләр белән күрешеп, тарих турында сөйләп, бик матур үтте. Шулай ук килгән яшьләр мастер-класслар белән генә түгел, ә үзләренә файдалы мәгълүмат та алып киттеләр.

Менә шушы проект яшьләргә тагын да ныграк оешырга ярдәм итте. Һәм безнең төп максат – менә минем Мәскәү өлкәсе татар җәмгыяте җитәкчесе буларак, төп максат – татар яшьләреннән лидерларны табарга. Чөнки татар яшьләрен җыярга кирәк һәрбер районда. Монда да менә шушы актив буенча без инде үзебезгә карадык. Менә шуның хәтле яшьләргә кемнәргә таянырга була, алар башка яшьләрне дә җыя ала. Менә шушылай лидерларны без әкренләп табабыз.

Шушы форумны без киләсе елга планга да керттек. Бөтенесенә ошады һәм бөтенесе дә шушы форумны тагын да киңәйтебрәк уздырырга дигән фикер белән риза булды. Ул ярдәм итә яшьләргә оешырга, бер-берен белергә, үсәргә, бер-берсе белән танышырга ярдәм итә. Чөнки матур-матур кызлар, матур-матур егетләр, бергә татарча сөйләшеп, бергә гапләшеп, төннәрен дә яртылаш йокламый, чөнки йоклыйсы килми, җыелганнар шундый матур урыннарда. Менә шундый очрашу безнең булды. Ул бик матур һәм бик файдалы булды.

Отчет турында инде, мин башта уйлаган идем сөйләгәндә грантның заявкадан башлап, аларын кирәкмидер монда сөйләргә. Чөнки күп кешенең проект язганы бардыр. Грантка язу өчен башта аның заявкасы кирәк. Заявкада кирәк аның иң беренче аның актуаль темасын табарга кирәк, чөнки тема ул кирәкле булырга тиеш. Бер чара гына узды түгел, минемчә, ул чараның дәвамы булырга тиеш.

Менә без уздырган чара “Молодежный форум” аның дәвамы булырга тиеш. Чөнки яшьләр белән постоянно эшләргә кирәк, һәрвакыт

эшләргә кирәк. Шуңа күрә бу уздырган форумнар, бер очрашкач шундый импульс бирә дә, аннан соң тагын да ел арасында менә монда җыелган тәҗрибә белән эшләргә мөмкинчелек бирә. Шуңа күрә, минемчә, менә монда бирелгән грантлар турында уйларга кирәк. Чыннан да, тема бер, ә аның эчтәлеге икенче булырга может, күбрәк булырга может. Моның шул ягы да бар.

Монда килер алдыннан, папканы әзерләп кертеп куйдым министерствога. Кичә генә дә кереп, тикшереп чыктым. Хатаны табалмадык әле диләр. “Мин әле монда тагын 3 көн булам, хатаны табарсыз, килеп төзәтеп китәрмен”, - дидем. Менә бу безнең 1нче проект турында.

Ә болай инде безнең Мәскәү өлкәсендә грантовая система бар. Главное управление социальных коммуникаций буенча ел саен конкурс оештырыла. Шул конкурс буенча без быел ук алдык грант гаиләгә багышланган. Менә яшьләр, аннан соң гаилә, татар гаиләсе. Гомумән гаилә – ул зур проблема бүгенге көндә. Минем бер бик зур киңәшче, профессор Усманов, ул бик яхшы информация белә. Гаиләләр оеша һәм яртысы аерылыша, чөнки яшьләр әзер түгел. Бүген ярату, иртәгә юк. Кыенлыклар килеп туа.

Шуңа күрә менә бу темага без проект ясадык, әлеге вакытта бу проект бара. Без үзебез Мәскәү өлкәсендә алып барабыз мастер-класслар шушы гаиләләргә багышланган. Һәм декабрьдә Мәскәүдә культура үзәгендә уздырачакбыз конфереция гаиләгә багышланган һәм ул грант буенча отчет безнең Мәскәү дәүләте каршында. Бу шулай ук бик актуал тема, бетми торган тема. Аны һаман үстерергә кирәк, һаман кирәк игътибар. Чөнки бүгенге көндә бөтенегез дә беләсез, гаиләләр кими. Гаиләләрдә сплоченность дигән нәрсә юк. Менә шуның өчен яшьләрне әзерләргә кирәк. Бу шулай ук безнең өчен актуаль тема.

Без барыбыз да күп сөйлибез. Менә балаларны тәрбияләргә кирәк татар телендә. Бу бөтенебез өчен дә зур сорау. Шуңа күрә без бер грант

ясадык. Ул балаларны гаиләдә тәрбияләү. Үзебезнең укыту комиссиясе буенча ясадык грант. Аның буенча христоматия ясадык һәм дискын электрон формада. Беренчесе, балаларга 3-4 яшькә хәтле, икенчесе 5-6 яшькә хәтле 10ар дәресле менә шушындый дәреслекләр әзерләдек. Гаиләләргә кереп, менә шушы христоматия белән дискларны биреп, аларны мотивировать итәргә, үз балалары белнә шөгыльләнергә. Әгәр дә шул гаиләдә булмаса, менә кичә генә бит ишеттек, гаиләдә сөйләшү булмаса, гаиләдә эти белән әни аңа игътибар итмәсә, аннан соң кыен.

Менә шушы проектыбызны шулай ук ясадык. Ул бездә бар. Һәм менә үзебезнең Шурада, Советта әйттек, әйдәгез әле менә бу елны татар теле елы дип үзебезнең автономиядә игълан итик. Менә шушы гаиләгә кереп эшләргә, шулай ук без шушы грант белән ясадык задел. Бу инде менә шушы Мәскәү Правительствосы буенча.

Тагын бер направление – безнең система субсидий бар. Без Сабантуй уздырабыз. Безнең Сабантуй ул күчмә Сабантуй Мәскәү өлкәсендә. Без аны ел саен эстафета сыман бер шәһәрдән икенче шәһәргә биреп җибәрәбез. Безнең Мәдәният министрлыгында Мәскәү өлкәсендә шулай ук конкурс бар, акчалар бирелә. Ләкин ул акчалар чара узгач, Сабантуйны уздыргач, менә шуның хәтле акча бирәбез, Сабантуйны уздыр, шул Акчага отчет бир, аннан соң ул акчаны аласың. Отчет ул зур папка булып чыга иде. Менә монды юл безнең шулай ук бар.

Һәм соңгысы, тагын акча килә торган нәрсәне әйтеп үтәсем килә. Мәскәү өлкәсендә премия губернатора Московской области. Анда берничә номинация. Шул номинацияләрдә, әлбәттә, менә шушы безнең направлениядә эшләгән эшләр буенча да бара. Быелгы премия, аны кемнәрдер белә инде, аны игълан да иткән идем, съезд краеведовта без бик матур китап чыгардык “Татары Подмосковья” дип атала иде ул. Шул китап буенча безгә шулай ук премия бирелде. Менә кичә генә 28е, анда как раз губернатор шул премияне өләшә иде. Мин монда, шуңа күрә мин

кайткач алам. Бу безнең эшләгән кешеләргә менә шундый поощрение. Ул шулай ук безнең өчен бик әйбәт.

Менә шундый юлларны мин кулланырга тырышам. Шул проектларның күбесен үземә эшләргә туры килә, чөнки үзең эшләмәсәң, башка кешене һәрвакыт табу җиңел түгел. Ләкин барыбер бу юлны кулланырга кирәк, чөнки бу юл акча китерә торган юл. Эшләмәгән алмый. Барыгызга да уңышлар телим. Әгәр дә сораулар булса, мин җавап бирергә әзер. Рәхмәт!

**Данис Шакиров**: Ничек килешәбез, сорауларны һәрбер чыгыштан соң бирәбезме яисә гомуми итеп азактан нәтиҗә ясап? Аңлашылды. Әле безнең вакыт бар. Соңыннан, алайса килештек. Бик зур рәхмәт сезгә! Хәзер мин сүзне Чувашия Республикасының Төбәк татар милли мәдәнияте мохтарияте советы рәисе Гыйбатдинов Фәрит Абдулла улына бирәм. Рәхим итегез!

**Фәрит Гыйбатдинов**: Әссәләмәгаләйкүм, хөрмәтле милләттәшләр! Чыннан да, бүгенге көннәр конгрессның йомгаклавы гына түгел, гомумән безнең мөселманнарыбыз алдында, татарларыбыз алдында Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) нең туган көннәре. Бөтен җирләрдә, бигрәк тә безнең Чувашстан җирендә Мәүлид бәйрәмнәре башланып китте. Сездә дә барабыр дип уйлыйм. Безнең иртәгә Урмай авылында, аннан соң Комсомол авылында, әкрен генә шулай авылларны йөреп чыгып, аннан соң башкалабызда Мәүлид бәйрәмнәрен бик матур итеп уздырабыз, Аллага шөкер.

Бу эшне эшләргә, билгеле, бернинди грант та кирәкми. Монда иң мөһиме Аллагы Тәгаләгә һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) гә мәхәббәт. Бу эшкә, Аллага шөкер, бөтен татарларыбыз булышып килә. Бу халык белән, халык мәхәббәте белән үтә торган бәйрәм.

Ә шәхси безнең тормышыбызда милли мохтарият булсынмы, башка татар иҗтимагый хәрәкәтләр булсынмы, Диния нәзарәте булсынмы, бүгенгесе көндә, чыннан да, яшәүнең бар гамәлләрен дөньяга ашыру өчен

телибезме-теләмибезме, капиталистик системада яшәгәч, барсына да кирәк матди чыгымнар. Бүгенгесө көндә барыгыз да беләсез, “грант” дигән яңа әйбер уйлап чыгардылар. Мин үзем 30 еллап шушы милли-мәдәни мохтарияттә, аның лидеры булып эшлим. Элгәре ул грантлар безгә булмаса да, шул ук эшләрне без эшли идек, билгеле. Ул вакытта башкача иде бит, заманасы. Анда күбрәк идеология иде. коммунистлар идеологиясендә булган кешеләр, без анда иҗтимагый хәрәкәт, барсы да акчасыз, барсы да чын күңелдән эшләнә торган эшләр иде.

Хәзер замана үзгәрде, кешеләр дә үзгәрде, ә мөнәсәбәт башка. Шуңа күрә ничек табарга мөмкин соң бу акчаларны? Билгеле, Россия күләмендә Президент Владимир Путинның гранты НКО оешмасы бирә торган акча инде ул. Анда зур миллиардлар бирелә. Әмма мин әйтә алам, дөрестән дә, безнең бөтен татар оешмаларыннан үтеп китә ала 1-2 оешма. Мин беләм, Новосибирскидан үтте бер оешма һәм Красноярскидан. Мин үзем шушы грантта 3-4 ел катнашып килдем. Күпме акча түктем, әмма беркайчан да үтә алмадым.

Аннан соң икенче проект, безнең грантлар җирле. Кем кайда эшли, шул җирлектәге дәүләт белән сөйләшеп, аралашып, һәр оешманың үзенең урыны бит инде, шуннан алырга тырышабыз. Аның да бер проект үтә инде безнең Чувашиядә.

Һәм өченче грант проекты инде ул. Безнең Татарстаннан алып килгән акчабыз инде ул. Татарстаннан мин һәр елны алып барам бер проект. Нигә алып барам? Беренчедән, эшләгән проектлары да уңышлы дип уйлыйм. Без бит инде Чувашстан Республикасында. Безнең бер оешма милли мәдәни мохтарият. Татарстан Республика гранты – ул заинтересован, бер төбәккә бер проект в основном үтә.

Аннан соң бөтен проектларны эшләү өчен үтәргә кирәк экспортная комиссия. Экспортная комиссия – ул Мәскәүдә бик көчле. Республикада, үзебезнең җирле төбәктә эшләп була, потому что анда өйрәтәләр, ничек проектларны ясарга, ничек эшләргә икәнлеген. Ә Татарстанда тагын

үзебезнең экспортная комиссия бар. Получается бөтен җирдә дә ничек матур язасың, матур дигән сүзнең мәгънәсен дәлилләп, ничек көчле язасың, әгәр инде андый сәләтегез бар икән, димәк ул кеше позитивта, алырга мөмкин. Ә бит тормышта практик яктан асыл эшләгән кеше яза белмәскә дә булдыра. Кызганычка каршы шундый кешеләр читтә кала.

Аллага шөкер, Татарстан Республикасында экспортный комиссиядә торучы кешеләр күбесе чамалыйлар. Төбәкләрдә практик эш ничек икән, бәлки шуңа күрә дә минем төшеп калганым юктыр. Кем белә, киләсе елларда ничек булыр. 2018дә үтермен дип уйлыйм инде. Ник дигәндә, Федераль Сабантуй Чабаксар шәһәрендә, җәлләп булса да, ахырда биререләр дип уйлыйм.

Менә монда тема турында әйттеләр. Ел саен яңа тема. Ул абсолютно дөрес түгел әйбер. Безнең телебез бер гомер буена, мәдәниятебез бер. Бер проектны 150-200 меңгә бер елда гына эшләп булмый. Безнең мәңге үтә торган шул проблемалар ул булырга тиеш системалы рәвештә. 10 ел да үтәргә мөмкин, 15 ел да үтәргә мөмкин. Менә шушы мәсьәләне ничек тә булса экспортная комиссиягә яки дәүләтебезгә җиткезергә кирәк.

Аннан соң безнең төбәкләрдә зур-зур фестивальләр үтә. Алар безнең татар дөньясында, татар мохитында зур роль уйный торган чаралар. Казакъстанда “Иртыш моңнары”, бездә “Урмай Зәлидә”, Татарстанда үзендә “Түгәрәк уен” үтә. Кызганычка каршы менә шул конкурслар әлеге грант-проектта югалып кала. Алар 3нче ел алды икән, башка елларны ала алмыйлар. Шуңа күрә ничек тә булса аны уйларга кирәк. Шундый зур проектлар татар халкының бренды булырга тиеш. Раз бездән телиләр икән яңа тема, без аны ясыйбыз. Ә шулай да безнең максатыбыз – шул бер үк эш булганга күрә, ничектер киләчәктә аны шулай эшләргә кирәк, чтобы ул алай булырга тиеш түгел, дип уйлыйм.

Язарга өйрәндек инде без, язабыз, язабыз, язабыз, язабыз. Балларны алабыз. Менә мин алдым быел “Караван мирас” дигән Чувашстанда яшәүче татарларның аутентик җыр-биюләренә, аннан соң чигүләренә һәм

башка уен коралларына багышланган, ел дәверендә үтә торган фестиваль. Ел дәверендә үткәрдек без аны. Мастер-класслар, семинар-практикумнар үткәрдек. Чувашстан белән генә чикләнмәдек, Ульянга да бардык, Чиләбегә дә бардык. Башка төбәкләргә дә бардык. Күрсәттек үзебезне, опробовать иттек бөтен материалны.

Менә шушы грантлар белән тагын нәрсәне решать итеп була? Һәрбер районда үзенең иҗади коллективлары бар. Бездә мишәр ансамбле бар, “Тамчы” ансамбле бар. Салаватта супер аутентик фольклор ансамбле бар. Һәм төбәк үзенчә яши. Безгә бит максат куелган, бурыч куелган – һәр төбәк үзенекен өйрәнеп, саклап, киләчәккә калдырырга преемственность.

Ә ничек калдырасың аны, когда бүгенгесе көндә музыкаль яктан балаларны тальянкага өйрәтер өчен, бер тальянка бүгенге көндә 150 мең. Әгәр дә без оркестр ясарга телибез икән тальянистлардан, 10 тальянка ул була үзе миллион ярым. Аның янына әле тальянка гына түгел, думбрасы да кирәк, курае да кирәк, баяны да кирәк основной теманы алып барыр өчен. Менә шуларны булдырыр өчен аның коллективы кирәк, аның чиккән читекле әбиләре кирәк, апалары, балалары кирәк. Бер пар читек 20 мең тора.

Ә ничек эшләп була соң аны? Була, менә шушы грантлардан аерым Мәдәният министрлыгы алалса үзенә шул, безнең бит үтә “Түгәрәк уен”. Анда безнең бар этноцентр. Менә шуларны эшләп, мониторинг ясап, киләчәктә безгә шул мониторинг аша үткән коллективлары өчен аларга уен кораллары ясатып, күлмәкләр бирү, аяк киемнәре сату турында... Менә шундый программалар кирәк.

Бүгенге көндә без алган 210 мең сум ул күпме инде? Аның белән нәрсә эшләп була? Аллаһның рәхмәте яусын, Татарстан Республикасы шундый грант булдырганы өчен. Бүгенге көндә татар мәдәниятен саклап калыр өчен зур предел түгел. Тем более бөтен субүектлар да эләгә алмыйлар. Кировта 3 оешма икән, аның бары берсе генә ала. Ә калган оешмалар ничек яши? Менә шундый эшләнелмәгән эшләр бик күп.

Аннан соң экспортная комиссиягә, раз эшлисең икән, һәрбер экспертная комиссия кешеләре белән аерым сөйләшергә тырышыгыз. Алар бөтенесе сезнең тормышны белмиләр. Аралашырга кирәк. Любой вакытта әгәр сөйләшмәсәгез, үзегезне үзегез пиарить итмәсәгез, ул экспортная комиссиядә нәрсә генә юк. Хәтта сезнең сайтыгыз ничек эшләгәнен дә сорыйлар анда. Әгәр дә сезнең сайтыгыз көндәлек мәгълүматын куеп бармаса, сезнең баллыгыз почти юк дигән шикелле. Баллыгыз кимеде икән, акчагыз кими инде.

Монда бер-берсе белән тоташкан. Зависимость бик каты күп инде. Менә монда утырып кына, ике минут сөйләшеп кенә безнең бернәрсәбез дә булмый. Безгә ничек тә булса булдырырга, конгресс ашамы, Мәдәният министрлыгы ашамы. Безгә обязательно кирәк менә шул примерный, ничек тутырырга икәнен. Менә шуны тутырып, һәр оешмага җиткезергә заявка формасын, аның максатын. Потому что бүгенге көндә Мәскәү проектында язып өчен, анда обязательно мактарга кирәк, что безнең гражданское общество, без за Российскую нацию. Хотя бы сезнең белән безнең башка максат – без татар милләте өчен. Шуларны язмасагыз, шуларны эшләмәсәгез, Мәскәү проектын бер кайчан да ала алмыйсыз. Бу, бәлки, икейөзлелектер, но акча кирәк булгачтан эшләргә кирәк.

Елыбыз тәмамланып килә. Мин начар ел димәс идем. Һәр ел саен без барыбыз да сезнең белән хәрәкәттә. Минем белгәнем, бер генә төбәк тә буш торганы юк. Кайсы вакытта әйтәләр: “Чувашстанда яхшы эшлиләр”, -дип. Начар эшләүче төбәк юк. Аның планкасы гына башка. Һәр төбәк үзенчә хәрәкәтләнә.

Бервакыт миңа берсе әйтә: “Менә бу еллар үтә инде, “Шома бас”лар белән, “Сабантуй”лар белән. Башка белән юк”, -ди. Ә бит шул ук “Шома бас”лар, шул ук “Урмай-Зәлидә”ләр, шул ук “Сабантуй”ларны эшләүче бөтен халыкның 5-10% гына бит. 90% безнең халкыбыз читтә. Ә 5-10% сез инде ул һәр төбәктә көне-төне эшләүчеләр. Әгәр дә без дә тукталсак

шушы эшләрдән, шул вакытта инде милләт күләмендә, дөнья күләмендә югалып калабыз. Шуңа күрә барыгызга да Аллаһ саулыгын бирсен.

Без 6 декабрьдә Чабаксар шәһәрендә үзебезнең милли мохтариятнең йомгаклавын ясыйбыз. Быел безгә дә татар мохитенә Чувашстандагы 30 ел. Аннан соң 20 ел элек без анда төзегән идек бөтентатар оешмасын, 10 ел элек автономия төзегән идек. “Караван” наследиесенең йомгагын ясыйбыз. 5 җирле художнигыбызның зур күргәзмәсен ачабыз.

Безнең бит инде авыллар көчле, сүз дә юк. Һәр авыл ТНВда “Без тарихта эзлебез” дигән тапшыруларын үткәрде һәм бүгенге заман техникасы белән авылларны төшереп, зур клиплар ясады. Шуның выставкасы була. Һәм 6сы көнне Чабаксарда Мәүлид белән тәмамлыйбыз.

Аннан соң иң зур вакыйгабыз, 8-9ы безнең танылган Тукай авылы үзенең татар мәктәбенең 150-еллыгын үткәрә. Вакытыгыз булса, рәхим итегез. Һәр авыл да бездә 150-еллык мәктәп бар дип мактана алмый. 150 ел ул архивка кергән. Бәлки 150 генә дә түгелдер, тагын да күбрәктер. Күрәсезме, безнең татар халкы нинди бай халык. Киләчәктә дә безнең халыкка 200-300 еллык мәктәпләрне күрергә халкыбызга насыйп булсын. Барыгызны да киләчәк Яңа еллар белән!

**Данис Шакиров**: Рәхмәт, Фәрит Абдуллович! Менә сезнең сайтка булган мәсьәләгә тукталып узасым килә. Менә, әлбәттә, дөрес әйтте Фәрит Абдуллович. Грант каралган вакытта без, мәсәлән, теге яисә бу проектны хуплап, аерым киңәшмәләрдә үз сүзебезне әйткән вакытта һәрвакытта әйтеп киләбез: “Менә бу проект яисә бу эш системалы эшләп килә торган эшчәнлекнең нәтиҗәсе”, -дип.

Безгә министрлыклар вәкилләреннән шундый җавап килә: “Ярый, яхшы, әйдәгез, (планшет алларында) менә бу оешманың сайтына кереп карыйк диләр”. Әгәр дә сез системалы рәвештә эшлисез дип әйтәсез икән, сайтларын кереп карыйлар, анда Яңа ел белән котлау узган елгы яисә тагын бер-ике чара. Анысы да “Татар информ”нан яки башка җирдән алынган. Хәзер Милли Шура рәисе Васил Габтелгаязович Шәйхразиев та

бу мәсьәләгә катгый рәвештә үз сүзен әйтте. Гомумән, аерым мониторинг ясыячакбыз. Аерым бу мәсьәләне карарга кирәк һәм сезнең дә игътибарыгызны шуңа юнәлтер идем.

Һәрбер оешманың зур күләмдә акча кирәк түгел. Бүгенге көндә техник ягын уйлаган вакытта да, аерым бер платформа нигезендә, информацион технологияләргә бәйле, сайтны ясап була. Һәрбер оешманың мөмкинчелеге үзләренә. Сайтта тулы күләмдә чараларны системалы рәвештә сез алып барасыз. Без аны быел бигрәк тә сиздек. Ни өчен дигәндә, чөнки әгәр дә сезгә теркәү вакытында тапшырылган Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының 2018 елга планын карасагыз, узган елны ул брошюрка форматында булса, хәзер инде ул китапчык. 400 якын чара анда. Әле ул сез тәкъдим иткән планнардан кыскартылып, иң эре чаралар кергән план. Ул әле бүген аерым расланачак.

Фәрит Абдуллович Сабантуй турында дөрес әйтте. Без сезне барыгызны да, әлбәттә, чакырабыз, аерым хатлар белән, аерым квоталар белән. 7 июль дип билгеләнде. Әлегә кадәр менә бу дата Чувашиянең Чабаксарда уза торган Федераль Сабантуйга киләсе елга мин сезне барыгызны да көтеп калабыз.

Без инде Шыгырданда авыллар Сабантуен бер гөрләтеп уздырган идек. Хәзер төп оештыручы Фәрит Абдуллович. Һәм менә бу Чабаксардагы Сабантуйны да, әлбәттә, хөкүмәт белән бергәлектә. Беренче оештыру комитеты узды. Шуңа күрә үзегезнең планнарыгызга да бу чараны кертеп куюыгызны сорар идем.

Аерым бу блоктан икенче блокка – ул регистрация мәсьәләсе, теркәү мәсьәләсе. Шуңарга тукталып узасым килә. Безнең монда Россия регионнарыннан гына татар оешмалары түгел, чит илләрдән дә килгән татар оешмалары җитәкчеләре һәм вәкилләре. Шулай ук бик актив эшчәнлек алып бара торган.

Барлык чит илләрдә дә регистрация узып булмый. Юридик яктан караганда, хәтта оешма җитәкчесенең имзасы белән үзенең тамгасы бар, менә ул инде регистрация узган дип атап була. Менә хәзер ике вәкилебез сөйлиячәк. Алар безгә теркәү мәсьәләсен һәм хисап мәсьәләсен, отчетность дигән әйбер бар, әлбәттә, юридик терминнар алар барсы да русча. Бу хисап һәм теркәү – ул Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгы тарафыннан үткәрелә. Шуңа күрә рус телендә сөйләүләренә гаеп итмәссез.

Мин иң беренче сүзне башта **Рауза Изаһетдин кызы Шаһиморатовага** бирәсем килә, Бөтендөнья татар конгрессының II класс юристы. Рауза ханым, сүз сезгә.

**Равза Шаһиморатова**: Исәнмесез, кадерле дуслар! Без бик шатбыз сезне Казанда, башкалабызда күрергә. Мой доклад будет основываться на государственной регистрации общественных объединений общественных организаций, поэтому я перешла на русский язык, т.к. для государственной регистрации необходимо будет обратиться в федеральные органы юстиции, которые занимаются государственной регистрацией общественных объединений.

Особенности правового положения общественных организаций определяются Федеральным законом Российской Федерации от 19 мая 1995 года N 82-ФЗ Закон «Об общественных объединениях».

Статьей 8 Закона № 82-ФЗ определено, что общественной организацией является основанное на членстве общественное объединение, созданное на основе совместной деятельности для защиты общих интересов и достижения уставных целей объединившихся граждан.

Членами общественной организации в соответствии с ее уставом могут быть физические лица и юридические лица – общественные объединения. Высшим руководящим органом общественной организации является съезд (конференция) или общее собрание. Постоянно действующим руководящим органом общественной организации является выборный коллегиальный

орган, подотчетный съезду (конференции) или общему собранию. Его, по вашему усмотрению, можете назвать как совет или же правление.

В случае государственной регистрации общественной организации ее постоянно действующий руководящий орган осуществляет права юридического лица от имени общественной организации и исполняет ее обязанности в соответствии с уставом.

Деятельность общественных организаций основывается на принципах добровольности, равноправия, самоуправления и законности. Общественные организации свободны в определении своей внутренней структуры, целей, форм и методов своей деятельности. Деятельность общественных организаций должна быть гласной, а информация об их учредительных и программных документах – общедоступной.

Какой же порядок учреждения общественных организаций? Порядок учреждения общественной организации установлен главой 2 Закона № 82-ФЗ. Общественные организации создаются по инициативе их учредителей - не менее трех физических лиц. В состав учредителей наряду с физическими лицами могут входить также и юридические лица - общественные объединения. Следовательно:

- один гражданин единолично не может учредить общественную организацию;
- юридическое лицо - коммерческая организация не может быть учредителем общественной организации.

Решения о создании общественной организации, об утверждении ее устава и о формировании руководящих и контрольно - ревизионного органов принимаются на съезде (конференции) или общем собрании. С момента принятия таких решений общественная организация считается созданной: она осуществляет свою уставную деятельность, приобретает права, за исключением прав юридического лица, и принимает на себя обязанности, предусмотренные законодательством.

Это важно! Общественная организация приобретает права и обязанности юридического лица только с момента государственной регистрации организации. Следовательно, общественная организация имеет право функционировать и без государственной регистрации. Однако в этом случае она не будет юридическим лицом, а, следовательно, и не сможет осуществлять самостоятельную хозяйственную деятельность. Если изначально общественная организация планируется как организация, которая не ведет хозяйственную деятельность, для ее легитимной деятельности права юридического лица (то есть государственная регистрация) не обязательны.

Учредителями, членами и участниками общественных организаций могут быть граждане, достигшие 18 лет, и юридические лица - общественные объединения. Органы государственной власти и органы местного самоуправления не могут быть учредителями, членами и участниками общественных организаций.

Условия и порядок приобретения, утраты членства, включая условия выбытия из членов общественных организаций по возрасту, определяются уставами самих общественных организаций. При создании общественных организаций их учредители автоматически становятся их членами, приобретая соответствующие права и обязанности.

Устав общественной организации должен предусматривать:

1) название, цели общественной организации, его организационно-правовую форму («Общественная организация»);

2) структуру общественной организации, руководящие и контрольно-ревизионные органы, территорию, в пределах которой организация осуществляет свою деятельность;

3) условия и порядок приобретения и утраты членства в общественной организации, права и обязанности членов организации (если организация предусматривает членство);

4) компетенцию и порядок формирования руководящих органов общественной организации, сроки их полномочий, место нахождения постоянно действующего руководящего органа;
5) порядок внесения изменений и дополнений в устав общественной организации;
6) источники формирования денежных средств и иного имущества общественной организации;
7) порядок реорганизации и (или) ликвидации общественной организации.

Устав общественной организации может содержать описание фирменной символики. В уставе могут предусматриваться и иные положения, относящиеся к деятельности общественной организации, не противоречащие федеральным законам. Официальное название общественной организации должно содержать территориальную сферу деятельности. Т.е. если от организации создается, и будет организоваться в одной территории местного самоуправления, то она так и называется – «Местная общественная организация».

Если организация, осуществляя свою деятельность в пределах одного субъекта Российской Федерации, то она называется «Региональная общественная организация». В названиях обязательно нужно будет указывать территориальную сферу деятельности. Также в Уставе в обязательном порядке указываются права организации и ее обязанности.

Про обязанности вам расскажет представитель из органов управления. А я в основном расскажу вам, какие же документы необходимы для того, чтобы зарегистрировать в территориальных органах министерства юстиции, какие необходимо предоставлять документы.

Решение о государственной регистрации общественной организации принимается федеральным органом исполнительной власти в области юстиции или его территориальным органом. Внесение в единый государственный реестр юридических лиц сведений о создании, реорганизации и ликвидации общественных организаций осуществляется

налоговыми органами. Т.е. орган, принимающий решения о государственной регистрации, соответствующее решение и пакет документов направляет в налоговый орган.

Далее этот орган вносит запись, и общественной организацией выдается выписка и свидетельство, где указывается полностью все данные в этой организации. Выдается свидетельство налоговой, а орган, принимающий решения о государственной регистрации, выдает свое свидетельство и Устав. Таким образом, 4 документа получает организация при принятии решения о государственной регистрации.

В первую очередь, необходимо заполнить заявление, подписанное членами постоянно действующего руководящего органа общественной организации, где указывается фамилия, имя, отчество, места жительство и контактные телефоны;

устав общественной организации в трех экземплярах;

выписка из протокола учредительного съезда (конференции) или общего собрания, содержащая сведения о создании общественной организации, с указанием полного наименования, об утверждении его устава и о формировании руководящих органов и контрольно-ревизионного органа.

Здесь есть методические рекомендации по заполнению этих бланков. Необходимо обладать определенными знаниями, чтобы заполнить все заявления. Все заявления не нужно заполнять, конечно же. Поэтому необходимо обратиться в регистрирующий орган, где вам окажут консультацию по этому поводу.

Предоставляются далее сведения об учредителях;

документ об уплате государственной пошлины;

сведения об адресе (месте нахождения) постоянно действующего руководящего органа общественной организации, по которому осуществляется связь с общественной организацией;

при использовании общественной организацией личного имени гражданина, символики, защищенной законодательством Российской Федерации об

охране интеллектуальной собственности или авторских прав, - документы, подтверждающие правомочия на их использование.

Указанные документы подаются в течение трех месяцев со дня проведения учредительного съезда (конференции) или общего собрания.

У меня все. Если вопросы есть, то, пожалуйста.

Залдан сорау.

**Равза Шаһиморатова:** Башта учределләр булалар. Аннан соң алар члены булалар общественной организации автоматически. Ул законда билгеләнгән.

Порядок приема и выхода из членства – все указывается в Уставе, права и обязанности, прием в члены, выходы из членства – все должно быть указано в Уставе, в учредительном документе.

Законда әйтелгән, граждане РФ могут быть учредителями, но также могут быть и учредителями иностранные граждане, которые законно проживают на территории Российской Федерации. Законда шулай дип әйтелгән.

**Залдан сорау:** Заменить? Вы знаете, заменить никак нельзя учредителями. Вот он при создании организации был учредителем и все, так и остался в истории. В ваших документах внутренних он в дальнейшем не принимает участия и все. А при создании он принимал участие и как бы остается учредителем.

Закрыть? Да. Вот ликвидация организации весь процесс указывается в учредительном документе в Уставе. Это предусмотрено законом.

Залдан сорау.

**Равза Шаһиморатова:** Ликвидировать общественную организацию хочет? Пожалуйста. Создается ликвидационная комиссия. Собрание не хочет? Ну как же так. В законе сказано, что высший орган принимает решение о ликвидации. Один человек не может принять решение. Высший орган должен принимать решение. Это все оговаривается при создании

организации. Принцип формирования при организации и ликвидации – все указывается в учредительном документе в Уставе.

Залдан сорау.

**Равза Шаһиморатова:** Конечно, это можно доработать. Т.е. внести изменения в Устав. Это нужно обратиться в регистрирующий орган по месту нахождения вашей организации, проконсультироваться со специалистами, как это сделать, какие формы вы должны заполнить. Предоставляется протокол обязательно. Вот таким образом.

Залдан сорау.

**Равза Шаһиморатова:** В обязательном порядке. Все данные физического лица, полностью паспортные данные, ИНН, местонахождение, адрес – все указывается. Есть специальные бланки. Я повоторяюсь, что определенными знаниями нужно обладать, чтобы заполнить эти документы, которая предоставляет нам налоговая служба.

Залдан сорау.

**Равза Шаһиморатова:** Нет, вас это не касается. Это просто создается юридическое лицо, общественная организация.

Залдан сорау.

